| Республика Татарстан<br><br>Совет Менделеевского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br><br>Менделеевск муниципаль районы Советы |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

30.04.2025 ел Менделеевск ш. № 305/1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Советының 2014 елның 8 октябрендәге
260 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2014 елның 8 октябрендәге 260 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4. Конкурс комиссиясе 8 кешедән тора».

1.2. 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «5. Конкурс комиссиясе төзелгәндә конкурс комиссиясе әгъзаларының дүрттән бер өлеше Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы карары белән, дүрттән бер өлеше Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы карары белән, ә икедән бер өлеше Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) Указы белән билгеләнә.».

1.3. 21 пунктка «конкурс комиссиясе әгъзалары видеоконференцэлемтә чарасы буенча конкурс комиссиясе утырышында катнаша ала.» сүзләрен өстәргә.

2. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2014 елның 8 октябрендәге 260 номерлы карарында 4, 5 пунктлар үз көчләрен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе урынбасары Л.К. Галеева